Туган телем - иркә гөлем, киңдер сиңа күңел түрем...

КҮЛӘК КӨЧ

ГОМУМИ РАЙОН ТАТАР ГАЗЕТАСЫ
1930 елдан чыга.
Бәясе ирекле
№ 1 (10693)
Чәршәмбе,
4 январь 2017 ел.
(Атнага бер тапкыр чыга)

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫЛАР: 1. УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ХӨКҮМӘТЕ (432017, Ульяновск шәһәре, Ленин мәйданы, 1)2. "ИСКЕ КУЛАТКЫ РАЙОНЫ" МУНИЦИПАЛЬ БЕРЛӘШМӘСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ (433940, Ульяновск өлкәсе, Иске Кулаткы эшчеләр бистәсе, Пионерская урамы, 30)

7 января – Рождество Христово
Дорогие земляки!

Пора зимних праздников – время, когда люди становятся ближе, а ссоры и обиды отступают перед торжеством светлой объединяющей божественной силы. Впереди – один самых главных праздников – Рождество Христово. Его всегда связывают с началом новой жизни, надеждой на лучшее, верой в добро и милосердие. Этот день мы стараемся проводить в окружении самых близких нам людей, говорить друг другу теплые слова и делать своих родных хоть чуть-чуть счастливей.

В сочельник и рождественскую ночь пройдут службы во всех больших и малых храмах нашей губернии. От величественного Спасо-Вознесенского и Германовского в Ульяновске до церквушки в Арбузовке. И везде будет по-своему тепло и уютно. Сам воздух наполнится добром в предвкушении волшебных перемен.

Дорогие друзья! Сердечно поздравляю вас с одним из самых светлых христианских праздников! Желаю вам крепкого здоровья, благополучия, счастья и радости, пусть исполняются самые заветные мечты!

Губернатор Ульяновской области С.И. МОРОЗОВ.

ТӨКЛЕ АЯГЫҢ БЕЛӘН, ЯҢА 2017 ЕЛ!

Һәр кеше күңеленә балачактан ук Яңа ел бәйрәме ниндидер серлелек, киләчәккә яңа матур хыял, өметләр уяту чоры булып кереп каладыр, мөгаен. Гадәттәгечә, быел да 31 декабрь көнне искекулаткылылар үзәк чыршы янында бергәләп иске елны озатты. Бу матур бәйрәмне халыкның көтеп алуын сизенгәндәй, табигать тә миһербанлылык күрсәтте – шимбә киче салкын булмады. Өлкәннәр дә, яшьләр дә, бала-чага да мәйдан тутырып күңел ачты. Үзәк чыршының күркәм бизәлеше һәркемне үзенә гашыйк итте. Мәйданга җыелган халык төрле төстәге утларның үзенчәлекле яктыртылышын сокланып күзәтте. Бәйрәм кәефе бөтен җирдә дә тоелды. Һәркемнең төп игътибары сәхнәдә булды. Биредә беркемне дә битараф калдырмаган үзешчән артистлар үзләренең осталыкларын күрсәттеләр, олысы да, кечесе дә шаян җырлар астында биеде. Райондашларын бәйрәм белән Иске Кулаткы муниципаль район администрациясе Башлыгы И. А. Аблязов, район Башлыгының урынбасары М. М. Бәширов, “Бердәм Россия” партиясенең башкарма комитеты җитәкчесе Л. Р. Амирова, район музее директоры Р. М. Байбикова котладылар. Яңа елга якты уйлар, ныклы максатлар белән керергә, туган җиребез, яраткан районыбызның чәчәк атуы, анда яшәүче кешеләрнең бәхетле булуы өчен барыбызның да сәламәт булып, яңа уңышлар яулавы мөһим, диелде җитәкчеләрнең котлау чыгышларында. Аларның сүзләрен бар халык та шау-гөр килеп, кул чабып хуплады. Аннары җигүле атта Кыш бабай белән Кар кызы да килеп җиттеләр. Алар сәхнә түреннән Яңа ел килүен игълан иттеләр һәм барлык халыкны тәбрикләделәр. Нәни балалар ашыгып-ашыгып шигырьләр сөйләделәр. Кыш бабай белән Кар кызы һәммәсенә дә татлылар өләштеләр. Чыршы тирәсендә әйләнә-бәйләнә йөрүләр булды. Бәйрәмнең төп бүләге булып күктә төрле утлар белән салют балкыды.

Гөлназ КУЗӘЕВА.

ДОРОГИЕ БРАТЬЯ И СЁСТРЫ! СЕРДЕЧНО ПОЗДРАВЛЯЮ ВАС С РОЖДЕСТВОМ ХРИСТОВЫМ!

Рождество Иисуса Христа – это ключевое историческое событие. Своей земной жизнью Господь Иисус Христос больше раскрыл нам природу Триединого Бога – Отца, Сына и Св. Духа.

До этого человечество не в полной мере знало о Боге и об истинных приоритетах в жизни людей с Его точки зрения. Так, например, есть такая заповедь: «Почитай день субботний. Шесть дней делай дела свои, а седьмой – посвяти Господу Богу твоему». Соблюдая эту заповедь в ветхозаветной эпохе, люди не только не трудились в субботний день, но и не дерзали преодолевать расстояние в 2000 локтей (это примерно 1 км). Когда Христа пытались осудить за то, что исцеляет больных в субботу, Он, обличая такое буквоедство, отвечал: «лицемеры! не отвязывает ли каждый из вас вола своего или осла от яслей в субботу и не ведет ли поить?» или по-другому - «Суббота для человека, а не человек для субботы».

В своей Нагорной проповеди Христос говорил: «Вы слышали, что было сказано (в прежние времена): “око за око, и зуб за зуб…”, “возлюби ближнего твоего, и возненавидь врага твоего”. Я же говорю вам: любите врагов ваших и молитесь за тех. Ведь если вы будете любить (только) тех, кто вас любит, какая у вас заслуга? Разве мытари (грешники) не делают того же? И если вы дружелюбны только со своими, что в том особенного? Разве язычники не делают того же?..

И следите за собой, чтобы дела праведности не творились у вас напоказ, для зрителей; иначе нет вам награды у Отца вашего, Который на небесах. Итак, если доброе дело делаешь, не учиняй шума, как делают в синагогах и на улицах лицедеи, ищущие похвалы от людей. Воистину говорю вам, они (уже) сполна получили награду свою. Но когда ты делаешь доброе дело, пусть левая рука твоя не знает, что делает правая, чтобы твое доброе дело было тайным; и Отец твой, видящий тайное, воздаст тебе.» (Евангелие от Матфея гл. 5)

А что Христос говорил о желающих властвовать: «кто хочет между вами быть бóльшим, да будет вам слугою; и кто хочет между вами быть первым, да будет вам рабом» (Евангелие от Матфея гл. 5).

Все эти слова были направлены на изменение укоренившихся в сознании людей той эпохи жестоких стереотипов мышления в сторону Божественной справедливости.

Это лишь малая часть Его учения - учения, которое до того было неизвестным, которое затем изменило духовные ценности на нашей планете.

Сегодня мы вновь с радостью встречаем Рождество. Пусть Богомладенец Христос родится в сердце каждого человека, т.е. пусть Его проповеди станут путеводительной звездой в нашей жизни.

Хочу также поздравить и тех, кто живёт в добрососедстве с христианами. Добрососедство – это когда людям разных национальностей и разных религий хочется жить вместе рядом. Такая жизнь возможна лишь в той среде, где свято хранятся заповеди Божьи, свои традиции и культура, где все чувствуют себя комфортно, где не приходится терпеть друг друга сквозь сжатые зубы, где ни одна из наций, даже если она доминирующая по численности, не позволяет себе быть «железобетонной», где слышат друг друга, где есть взаиможертвенность.

Необходимо дорожить нажитым нашими предками опытом совместной жизни и передавать его будущим поколениям, созидая единое будущее и укрепляя наше многонациональное и многоконфессиональное государство.

С Праздником! С Рождеством Христовым!

Илья АРЛАНОВ, протоиерей, с. Чувашская Кулатка.

ПӘНҖЕШӘМБЕ (5.01.)	ҖОМГА (6.01.)	ШИМБӘ (7.01.)	ЯКШӘМБЕ (8.01.)	ДҮШӘМБЕ (9.01.)	СИШӘМБЕ (10.01.)	ЧӘРШӘМБЕ (11.01.)
- 4	- 19	- 18	- 3	- 14	- 14	- 11
- 15	- 19	- 30	- 18	- 20	- 16	- 19

ЯҢАЛЫКЛАР



Владимир Путин: "Узып баручы 2016 ел гади булмады, әмма авырлыклар Россияне берләштерде. Россия Президенты россиялеләргә "җиңүләр һәм казанышлар, аңлашу һәм ышаныч, Россияне чын йөрәктән кайгырткан өчен" рәхмәтен җиткерде. Без эшлибез, уңышлы эшлибез һәм безнең күп вакытта барысы да килеп чыга", - диде Путин.

● ● ●

Россия Президенты Владимир Путин Сергей Шәкуровка 75 яшьлеге уңаеннан котлау юллады. Сергей Шәкуровның әтисе Каюм Тәтеш районыннан, актерның балачакта "Сабир" дип атап йөрткәннәр һәм үзен татар санавы хакында әйткәне бар. Сергей Каюм улы Шәкуров Мәскәүдә 1942 елның 1 гыйнваренда рус-татар милләтләреннән булган катнаш гаиләдә туган. Әтисе — Тәтеш районы Бакырчы авылында туган Каюм Шәкуров, профессиональ аучы. Әнисе — Щеглова Ольга Сергеевна, совет рәссамы, карикатурачы Евгений Щегловның апасы.

● ● ●

Россиянең элемтә һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгы илдә рус телле интернет сегментын саклау юнәлешендә яңа закон проектлары эшли. Россиядә интернет өзелә икән, халык бу ситуациягә әзер булырга тиеш, дип белдергән Владимир Путинның интернет буенча киңәшчесе Герман Клименко RTга биргән интервьюсында.



Яңа ел алдыннан Ульяновскиның Татар мәдәният үзәгендә өлкә татар милли-мәдәни мохтарияте Башкарма комитетының киңәйтелгән утырышы узды. Анда милли оешма тарафыннан ел дәвамында башкарылган эшләргә нәтиҗә ясалды һәм киләсе елга эш планы расланды Өлкә губернаторы администрациясенең стратегик үсеш идарәсе башлыгы Сергей Паховский төбәк башлыгы Сергей Морозовның җылы тәбрикләү сүзләрен ирештерде. Татар мохтарияте өлкәдә генә түгел, ил күләмендә иң яхшы эшләүче милли берләшмәләрнең берсе булып санала, без моның белән горурланабыз һәм татар җәмәгатьчелегенә рәхмәтебезне җиткерәбез, диде ул.

● ● ●

Ульяновск өлкәсендә Димитровград Җәмигъ мәчетенең 120 еллыгын билгеләп үтте. Борынгы мәчетнең урам ягына караган диварында, биредә элек эшләгән имамнар истәлегенә, ике мемориаль такта ачылды. Үз гомерендә нинди генә тетрәндергеч вакыйгаларны кичергән, нинди генә мәсхәрәләүләргә дә түзеп калган мәчет бүген исән, Идел буе төбәгендәге иң абруйлы, иң шәрәтле Аллаһы йортларының берсе. Өлкә Губернаторы С.И. Морозов үзенең котлау телеграммасын юлларга.

● ● ●

Губернатор С.И. Морозов инициативасы белән 2017 елда регионда Эшмәкәрлек елы игълан ителде. Яңа елда өлкәдә барлык көчләр өч юнәлешкә җибәреләчәк: институциаль өлкәдә комплекслы ревизия ясау, регионда бизнес-миграциягә мөмкинлекләр булдыру һәм эшмәкәрлек эшен популярлаштыру.

● ● ●

2016 елда өлкәдә 14 мең 700 бала дөньяга туды. 1 январь көнне Губернатор С.И. Морозов өлкә клиник больницасында булып, Яңа елда бала табучы әниләрне тәбрик итте. Ә инде ЗАГС службасы хезмәткәрләре әниләргә бала туу таныклыклары тапшырдылар.

Государственное учреждение - Отделение Пенсионного фонда Российской Федерации по Ульяновской области

ИНФОРМИРУЕТ

С 01.01.2017 размер материнского капитала для владельцев государственных сертификатов, не воспользовавшихся правом распорядиться средствами сертификата, составляет 453 026 руб.

Напоминаем, что при распоряжении средствами материнского капитала, размер его уменьшается на сумму израсходованных средств.

ИТОГИ КОНКУРСА

В соответствии с рекомендациями Правительства Ульяновской области (распоряжение от 31.10.2016г. № 612-пр «О проведении месячника по организации эффективной работы по предупреждению и ликвидации задолженности граждан по оплате за жилое помещение и коммунальные услуги») в период с 01.11.2016г по 30.11.2016г. администрацией муниципального образования «Старокулаткинский район» на территории Старокулаткинского района проведен месячник по организации эффективной работы по предупреждению и ликвидации задолженности граждан по оплате за жилое помещение и коммунальные услуги.

За ноябрь месяц начислено населению за жилищно-коммунальные услуги 585,0 тыс. руб., собрано - 615,2 тыс. руб.; процент сбора за ноябрь составил 105,2%, что показывает хорошую эффективность проведения месячника.

В целях поощрения добросовестных плательщиков за жилищно-коммунальные услуги и стимулирования граждан к повышению платежной дисциплины администрацией муниципального образования «Старокулаткинский район» был объявлен конкурс «Добросовестный плательщик» (Постановление администрации муниципального образования «Старокулаткинский район» от 02.11.2016г. №333).

Погасив задолженность за жилищно-коммунальные услуги в срок до 1 декабря 2016г., все жители Старокулаткинского района могли принять участие в данном конкурсе.

Конкурс проводился в два этапа: отборочный тур и финальный розыгрыш призов. Жители района, которые по состоянию на 1 декабря 2016 года не имели задолженности по оплате жилья и коммунальных услуг, в период месячника автоматически стали участниками отборочного тура конкурса.

В отборочном туре приняло участие 809 лицевых счетов, участниками конкурса стали 30 плательщиков.

Финальный розыгрыш проводился 26 декабря 2016 года, победителями конкурса стали:

1. Фахретдинов Адельша Хусаинович;

2. Клявлина Фявзия Касымовна;

3. Исхаков Камиль Алимжанович.

Им были вручены благодарственные письма и памятные призы.

Так же благодарственное письмо и памятный приз вручены контролеру ОГКП «Радищевский групповой водовод» Татлыевой Дание Фяттяховне за активное участие при проведении месячника по ликвидации задолженности за жилищно-коммунальные услуги и конкурса «Добросовестный плательщик».

РӘХМӘТ ХАТЛАРЫ

РӘХМӘТЕБЕЗНЕ КАБУЛ ИТЕП АЛЫГЫЗ

Яңа ел алдыннан һәммәбез дә ниндидер могҗиза көтәбез, якыннарыбызны бүләкләр белән куандырырга тырышабыз. Иске Кулаткы районы Башлыгы Э. Ә. Ганеев, гадәттәгечә, быел да районыбызда яшәүче һәрбер баланы татлы бүләкләре белән куандырды. Иске Кулаткы беренче номерлы урта мәктәбендә дә гөрләтеп Яңа ел иртәләре үткәрелде. Мәктәпнең һәрбер укучысы да район Башлыгы Э. Ә. Ганеевның бүләгенә ия булды.Барлык ата-аналар, укытучылар һәм балалар исеменнән Э. Ә. Ганеевка күрсәткән кайгыртучанлыгы һәм тапшырган бүләкләре өчен изге рәхмәт сүзләребезне җиткерәбез. Авыр хезмәтегездә уңышлар, гаилә бәхете һәм саулык-исәнлек теләп калабыз.

ЯРДӘМГӘ АШЫКТЫЛАР

Кеше үзенең гомерендә нинди генә сынауларга, бәлаләргә дучар булмый. Күптән түгел генә безнең гаиләне дә көтмәгәндә кайгылы вакыйга сынады. Бертуганымның кызы, Динара, чанадан шуыганда егылып, умырткалыгын (позвоночник) җәрәхәтләде. Әлеге авыр чакта бар өмет табибларда иде.

Беренче булып, без авыл ФАПының шәфкать туташына Гөлнур Дәүләтшовна Хәбибуллинага шалтыраттык. Ул бар эшен калдырып, кыска вакыт эчендә безгә килеп җитте һәм Динараны карап, Иске Кулаткы район больницасына илтү кирәклеге турында әйтте. Вакыт санаулы булганга, әлеге ханым үз улының машинасында безне район үзәгенә җиткерде.

Биредә дә безгә зур игътибар күрсәттеләр. Дежур врачы Фәргать Гаязович Абитов авыруны карап, өлкә табиблары белән элемтәгә чыкты һәм авыруның хәле турында сөйләде. Чөнки әлеге хәлдә өлкә табибларының ярдәме бик мөһим иде. Ә инде больницаның Баш табибы Сергей Александрович Кунеевский хәлебезгә керешеп, өлкәгә баруны оештырды һәм ашыгыч ярдәм машинасы бирде.

Авыл шәфкать туташына, Иске Кулаткы район больницасы табибларына шундый ярдәмчел, аңлаучан, җаваплы, һөнәрләренә тугры, үз эшләрен бар күңелләрен биреп башкарулары өчен олы рәхмәт сүзләре әйтәсе килә. Авыр, җаваплы хезмәтегез Сезгә һәрчак шатлык кына китерсен, авырулар һәрвакыт рәхмәт сүзләре генә ирештерсен иде.

Форсаттан файдаланып, шулай ук материаль ярдәм, кайгыртучанлык күрсәткәннәре, кыен чакта ярдәм кулы сузганнары өчен авыл мәчетенә, мәктәп коллективына һәм авылдашларга олы рәхмәтләребезне җиткерәбез. Исән-сау булсыннар, Аллаһы Тәгалә беркемгә дә бәла-казалар күрсәтмәсен.

Рузалия АХТӘМОВА.
Мосеевка авылы.

ВЕТЕРАННАРНЫ КОТЛЫЙБЫЗ!

2017 елның январь аенда районыбызда гомер кичерүче Бөек Ватан сугышы ветераннары Рәшит Исмаилович Ханбиков (Иске Кулаткы), Сабирҗан Шакирович Рәхмәтуллин (Яңа Кулаткы) узләренең туган көннәрен билгелиләр.

ХӨРМӘТЛЕ ВЕТЕРАННАР!

Район ветераннар Советы Сезне истәлекле туган көннәрегез белән тәбрик итә. Илебез азатлыгы өчен көрәштә күрсәткән батырлыгыгыз алдында баш иеп, Бөек Җиңүне яулап кайтканыгыз өчен, Сезгә олы рәхмәт белдерәбез. Исәнлек-саулык, гаиләгезгә иминлек, тынычлык һәм якты көннәр телибез. Якыннарыгызны шатландырып, озын гомер итегез!

Район ветераннар Советы Бөек Ватан сугышы ветераннарына тиңләштерелгән **Абдулкәбир Ибраһимович Рамаев (Иске Зеленай), Бөек Ватан сугышының соңгы чакырылыш солдаты Абдулхай Юсупович Ханбиков (Иске Кулаткы), Бөек Ватан сугышының тыл хезмәтчәннәре Фаилә Хәйдәровна Аминова (Бахтеевка), Халимә Сабировна Насырова (Иске Мостяк), Сәйдә Люкмановна Богдалова (Вязовый Гай), Шәфика Үмәровна Ханбикова (Иске Кулаткы), Рәшидә Мәҗиповна Нугаева (Иске Кулаткы), Зөләйха Изятовна Усманова (Иске Кулаткы), Анна Васильевна Хурасева (Чуваш Кулаткы), Рәшидә Ибраһимовна Вяльшина (Иске Атлаш), Адилә Каюмовна Кузәева (Иске Зеленай), Равил Хөсәинович Алиакберов (Югары Терешка), Халисә Хөсәиновна Байбикова (Урта Терешка), Разия Мостафовна Фәйзуллина (Урта Терешка), Сәйдә Шакировна Аббәсова (Иске Атлаш), Рәйсә Абдулловна Мөслимова (Иске Атлаш), Хатимә Сагировна Абитова (Иске Атлаш), Наилә Сөләймановна Абдюкова (Иске Мостяк), Антонина Васильевна Пайдулова (хутор Кольцовка)**, Бөек Ватан сугышы елларында туган балалар статусын йөртүче һәм январь аенда үзләренең олы юбилейларын билгеләп үтүче **Равза Ибраһимовна Абәйдуллина (Вязовый Гай), Зәкия Сөләймановна Алиева (Мосеевка), Ибраһим Якубович Алтынбаев (Иске Яндука), Рәшидә Яхъевна Ахметова (Иске Мостяк), Сәгадәт Рызвановна Бекерова (Иске Зеленай), Тәүфыйк Җәннәтханович Бикбаев (Иске Зеленай), Сания Исхаковна Гафурова (Яңа Мостяк), Румия Якубовна Зәйнетдинова (Иске Зеленай), Фәридә Әхмәдиевна Кадермәтова (Иске Кулаткы), Нина Петровна Каратаева (Иске Кулаткы), Гөлсария Абдулхаевна Кәримова (Яңа Зимница), Венера Фатиховна Касимова (Яңа Терешка), Румия Яхъевна Кузәева (Яңа Терешка), Тәскирә Исмаиловна Кузәхметова (Иске Мостяк), Нурия Рәхимҗановна Кушаева (Кирюшкино), Марс Җиргҗисович Мәгдиев (Иске Кулаткы), Флора Нурулловна Мәгдиева (Карамалы), Маһирә Исхаковна Мусеева (Иске Кулаткы), Сәгадәт Аббәсовна Нагаева (Яңа Зеленай), Ришат Фәтхуллович Надршин (Иске Мостяк), Нәҗия Абдрәшитовна Рәхмәтуллина (Иске Зеленай), Әминә Идрисовна Сәйфетдинова (Югары Терешка), Дамирә Ибраһимовна Салихова (Яңа Зеленай), Фикки Сабирович Улюкаев (Иске Кулаткы), Расим Исхакович Усманов (Яңа Зимница), Сәгадәт Усмановна Усманова (Иске Мостяк), Наилә Абдулһадиевна Утәева (Яңа Кулаткы), Роза Закировна Фәйзуллина (Яңа Терешка), Мөнир Имадиевич Хәбибуллин (Иске Кулаткы), Алимә Үмәровна Хәбибуллина (Югары Терешка), Равил Мостафович Хәйруллин (Иске Атлаш), Мөнҗия Мотыйгулловна Хөснетдинова (Иске Мостяк), Рәшит Батырханович Юсупов (Иске Зеленай), Якуб Хасанович Яфаровны (Карамалы)** чын күңелдән олы бәйрәмнәре белән тәбрик итә. Дәһшәтле сугыш елларында дөньяга килеп, шатлыклы, борчу-хәсрәтсез, михнәтсез балачактан мәхрүм булдыгыз. Әмма сугыштан соңгы елларда илебезне торгызуда, халкыбыз, киләчәк буын рәхәт тормышта яшәсен өчен, гомер барышында куп тырыштыгыз, узегездән өлеш керттегез. Сезгә саулык-сәламәтлек, гаилә бәхете, җан тынычлыгы телибез. Киләчәк тормышыгызда да саулыкта, муллыкта, якыннарыгызның игътибарын, җылысын тоеп яшергә насыйп булсын.

Хөрмәтле ЮБИЛЯРЛАР!

Сезнең тормыш юлы
- матур тарих,
Күпләр өчен үрнәк
булырлык.
Рәхмәт, дибез,
сезгә чын йөрәктән
Сезнең гомер -
безнең горурлык.



БЕРГӘЛӘП УКЫЙБЫЗ

ÊÖÒÅÏ ÓÇÃÀÍ ÃÎÌÅÐ

Повесть

Зифа Кадырова

Рушания ике көннән соң кайтканда өйдә беркем дә юк иде, ул өй уртасына басып, ары әйләнде, бире әйләнде, зур өй беренче тапкыр буш һәм салкын тоелды. Бик кирәкле нәрсәсен оныткандай, як-ягына каранды, ни эзләде - үзе дә аңламады. Зур өйнең почмагына күтәрелеп карады, почмактагы ярык тагын да зурая төшкәндәй тоелды. Рушания ул ярыкны якынрак килеп карамакчы булды, әмма анда бернинди дә ярык юк иде. Ул бермәлгә тынсыз калып карап торды, аннан авыр сулады. Өй түгел, гаиләм урталай ярыла бит. Ике битендә ялтыр юллар калдырып, күз яше тәгәрәде. Рушания авыр адымнар белән көчкә үзләренең йокы бүлмәсенә күтәрелде, хәле бетеп, үзләре йоклый торган караватка килеп утырды. Өстәл өстендә торган икесенең фотосына күзе төшүгә, йөрәге сулкылдап куйды. «Саша, авыр миңа, нишләдең син?» дип пышылдады. Күпме йөрәк әрнеше иде аңарда, берүзе генә белә дә, Ходай гына күрә. Рушания тәрәзәдән тышка - бакчасына карады, алмалар өлгерә, август уртасы җиткән. Элек булса, бу мәлдә Рушания шатлана-шатлана кышкылыкка компот, кыяр-помидор ябар, ут янып бакчасында кайнашыр иде, ә бүген бөтен нәрсә җир өстендә ята. Әнисе исән булса, әйтер иде: «Бу вәхшилек, балам, җирдә үскәнне алып эш итмәскә», - дияр иде, тик аның хәле дә, теләге дә юк. Рушания бераз уйлап торды да, Саматка шалтыратып чакыртты. Самат килгәч:

- Кыен булмаса, шушыларны җыеп, Хәлимәнең балаларына илтеп бирче, мин берни дә эшли алмыйм, сора, нинди ярдәм кирәк балаларга, - диде.

Рушания беркайчан да акча сорап утырмады, Саша үзе белеп кирәкле урынга сала, кемгә күпме кирәк - шул чаклы ала иде. Тик соңгы вакытта оныта башладымы, әллә башка җиргә күбрәк китә идеме, кирәкле урында акча юк иде. Ни генә булмасын, хәзер акча сорамаячак. Ул уңайсызланып кына Саматка карады.

- Акча калдырмаганнар икән, гафу ит, икенче юлы җибәрермен, - диде.

Рушания үзен бу гаиләгә бөтенләй кирәксез итеп тоя башлады. Ничек кенә булмасын, азмы-күпме калган гомерен беркемгә дә авырлыгын салмыйча, сынмый-сыгылмыйча тәмамларга иде дә бит, юк шул, көче җитми. Көне-төне йөрәген талаганы чире түгел, ә иренең хыянәте иде. Ярый әле балалары берни дә сизми. Тагын кич җитә, кичке аш .әзерләргә кирәк, кичке ашлар да газапка әйләнә башлады. Һәр өстәл артында чит кешеләр булып утыру, һәркем үз эченә бикләнеп алдындагы ашны болгату. Рушания аны, ә ул башканы уйлавы, күңеле белән бөтенләй башка җирдә йөрүе... Рушания аның күңеле белән кайдалыгын яхшы аңлый, ике арада урнашкан авыр тынлык иңнәрне баса, башны аска бөгә, күзләр очрашудан курка. Кичен йокларга ятар вакыт җиткәч, гомер иткән ире алдында эчке күлмәктән дә калырга читенсенә башлады, алар берсүзсез читләшкәннән читләштеләр. Тик әлегә берсе дә, безгә ни булды, дип, бер-берсенә сорау бирмәде, һәркайсысы ачыктан-ачык сөйләшүдән курыкты. Рушания үзен, «ярый, мин барыбер озакламый үләм», дип юатырга тырышты. Ни генә булмасын, гомер иткән бердәнбер якын кешең ниндидер җилбәзәк кыз өчен бергә үткән утыз елга якын гомерне, күз алмасы кебек балаларны онытып, шул балаларны бүләк иткән аналарын да ашаклап үткәнен аңлый иде микән? Кеше шулчаклы да үзгәрә ала дип, Рушания башына да китерә алмады, ә ул үзгәрде. Гашыйк кеше әзрәк җүләрләнә диләр, ул да бер акылсызны хәтерләтә башлады. Чәчен генә буятуы гына җитмәгән, мыек үстерә башлады, беркөнне чәч белән бергә анысын да буятып кайтты. Рушания мондый үзгәрешләрне күргән саен йөрәгә сикереп куйды, нишлисең син, ник кеше көлдерәсең, дип кычкырасы килде, Никтер эндәшә дә, кычкыра да алмады, шым гына читтән күзәтүчегә әйләнде. Тик кызы Алеся гына тыелып кала алмады:

- Әти, сиңа ни булды, буяна башладыңмы, әллә шулай яшәрәсең киләме?

Саша кызарып башын аска иде.

- Ярыйсы, сиңа мыек килешә. Әни, сиңа ошыймы? Сиңа да чәчеңне буярга вакыт, соңгы вакытта ак чәчләрең күбәеп китте.

- Әнә шул әтинеке каралганга әнинеке тизрәк агара, - диде Игорь.

Әтисенә сөзеп кенә карап алды да, бөтенләй өстәл артыннан торып чыгып ук китте. Рушаниянең йөрәге кысылып куйды, әллә бераз нәрсә белә микән, дип куркуга ук калды. Яхшы түгел балалар белсә. Аталары белән телгә килүләрен теләми иде, аларга аталары белән каласы. Рушания тагын кинәт шыбыр тиргә батты, үзендә хәлсезлек тоеп, кулын кесәсенә тыкты. Куллар калтырады, кесә эченнән генә даруын кубарып чыгарып каба алмыйча җәфаланды. Саша да үзен бик тыныч тотарга тырышса да, борчулануы сизелеп тора иде. Балалар берәм-берәм шәһәргә җыена башладылар. Аларга шундый зур өйдә икәүдән-икәү генә калу читен һәм авыр иде. Рушания хәле бик шәптән булмагач, өстәл артыннан кузгалмыйча утыра бирде. Менә бит тормыш, нигә барып җитте, я кайтмады, кайтса, сөйләшер сүз тапмады.

Рушанияләрнең шәһәрдә дә өч бүлмәле, үзләре элек яшәп киткән фатирлары бар иде. Ул анда аена бер булса да, барып тузаннарын сөртеп, караштырып кайта. Бүген дә Самат белән больницадан кайтышлый кереп чыгарга булды, инде бүтән килеп йөри алмаса, киемнәрен алып китәргә булды. Өй күлмәге, халатларын сумкага тутырды, булган гөлләргә су сипте, үзләренең йокы бүлмәсенә бик озак карап торды. Бәхетле чаклары шушында үтте, балалары шушында үсте. Ул акрын гына балалар бүлмәсенә үтте, бәлки әле оныклары да шунда туып-үсәр. Кинәт ишек ачылган тавыш ишетелде, Рушания сискәнеп китте. Артына борылуга, почмактагы шифоньер кәзгесенә күзе төште - аннан тышкы ишек күренә иде. Ишектән кергән Саша белән яшь кызны күргәч, бермәлгә урынында таш кебек катып калды. Алар ишектән керүгә үбешә башладылар. Рушания көчкә кузгалып стенага сыенды, акрын гына ишек артына шуышты, егылып калудан курыкты, тешен кысып күзен йомды. Ахрысы, алар йокы бүлмәсенә күчтеләр, мышнаган, карават шыгырдаган тавышлар ишетелде. Рушания тагын да тешен ныграк кысты. Теге кыз телгә килде:

- Ике көн килмәдең, сагынып үлә яздым. Татарочкаң өйдән чыгармадымы? Көнләшеп үләм дип торам, син аның белән дә булдыңмы?

- Юк инде, курчагым минем, синең белән булганнан бирле якын да барганым юк, мин бит сине генә яратам.

- Яратасыңмы, алайса теге кибеттәге матур тунны алып бирче, озакламый көз дә җитә, ә минем кияргә дә юк.

- Нишләп булмасын ди, Анталиядан алып кайттык бит.

- Ярый, вакланма инде, сиңа чүп кенә бит инде - нибары ике йөз мең сум гына тора. Хатыныңа әллә ниндиләрне кидерәсеңдер әле.

- Ул бит минем балаларымның анасы.

- Мин дә сиңа бер бәби табып бирәм, мин сиңа күпме яшьлегемне, назымны бирәм. Синең картайган татарочкаң ни бирә ала сиңа? Аерыл да, ул монда торсын, без синең белән урманда яшәрбез, чөнки яшь балага саф һава кирәк. Синең кебекләр бөтенесе хатыннарын алыштырып бетерделәр, ә син һаман аерылырга куркып йөрисең. Ә беләсеңме, без синең белән чит илдә чиркәүдә венчаться итәчәкбез, хәзер бик модно чиркәүгә йөрү.

Рушания ике колагын кысып япты, йөрәгә сикерә башлады, аның дөпелдәве бөтен өйгә ишетелә кебек тоелды. Үч иткәндәй, даруы сумкасында машинада калган. Күрше йокы бүлмәсендә ахылдашкан-ыңгырашкан тавышлар ишетелә башлагач, Рушания түзмәде, аяк очына гына басып, ишеккә юнәлде. Күрсәләр күрерләр - ишеккә карамый гына узып китте. Акрын гына ишекне ачып чыкты. Лифтка кергәч, башының чатнап авыртуы, иреннәре кибүен тойды. Тышкы ишекне ачуга, каршысында торган Саматны күреп беләгенә ябышты, «тизрәк өйгә», дип пышылдады. Самат күпме генә, кире больницага борылыйк, дип карамасын, ул һаман өйгә, тизрәк өйгә, дип ашыктырды. Самат күпер өстенә җиткәч, машинаны туктатты, алар каршысында Илья Ильич басып тора иде. Ул килеп ишекне ачты да Рушания алдына чүгәләде.

- Рушания, әйдә, уколыңны кадыйк. Үзе үк сумкасыннан актарып алып, аз гына итәген күтәреп, ботына уколны батырды.

Самат эшнең нидә икәнен яхшы аңлады, шикләнгән иде шул, ни булгандыр инде анда. Самат, сорап, авырткан җиренә тимәскә булды. Ул инде өй кырыена Александр Иванович килеп туктап, чит хатын-кыз белән кереп киткәч, башта куркуга калды, аннан хәлләр начар бетәчәген чамалап, Ильичка шалтыратып, хәлне сөйләп бирде. Ул: «Әенә алып кайтырга ашыкма, өендә үз эченә бикләнергә бирмә, сөйләштер, берәр җиргә алып бар, озакламый бушасам, үзем дә килеп җитәрмен», - диде. Күп тә тормады, үзе дә килеп җиткән.

- Самат, әйдә, акрын гына минем арттан бар.

Илья үз машинасына утырды да, Белоус урманына юл тотты. Бик матур бер аланга җитеп туктады. Аннан төшеп, Рушания утырган яктан килеп ишекне ачты. Рушаниянең кан качкан йөзенә бераз карап торды да, маңгаена төшкән бер буй ак чәчен артка сыйпап куйды. Әле ничә генә ай вакыт үтте, ул аның чибәрлегенә хәйран калган иде: йөзендә, әйтерсең, ай кунган, серле дә, сөйкемле дә иде. Ә менә хәзер аның түгәрәк йөзенә, айны куып, өнсез газап менеп урнашкан. Илья аңлый: авыртуны дару белән басып була, ә мондый хәлдә... Мондый хәлдә тик вакыт кына дәвалый ала, анда да вакыты булса, ә аның бу хәлендә... Көтмәгәндә килеп чыккан чире дә, хыянәт газабы да калган азмы-күпме вакытны ашыктыра иде. Әйтерсең, язмыш аңа арты белән әйләнде. Сабырлыкка күнгән Рушания ничек кенә хәлен яшерергә теләмәсен, язмышына төшкән сынау чирдән күпкә олырак, авыррак иде. Маңгай өстендә, чигә тиреләрендә ак чәчләр күренде. Бөтен авыр булмышын ничек кенә эчкә яшерергә тырышмасын, матур көрән күзләргә карау белән аңларга була - ничаклы авыр аңа бүген. Куе керфекләр дә шул авырлыкны күтәрә алмыйча, йомылырга гына тора иде. Илья, хәленнән килсә, бар авырлыкны үзенә алыр да, бу мөлаем һәм сөйкемле хатыннны шул авыр газаплардан азат итәр иде. Ул чак кына аның кулына кагылды, аның газап эчендә янган йөзеннән күзләрен алмыйча бик озак карап торды. Аның кулын үз учларына алып ирененә тидерде. Берсүзсез генә күзәтеп утырган Самат бу яшь егетнең хәлен аңлагандай булды, аның карашларында әйтеп бетергесез наз һәм сөю иде. Саматның да үзе әле генә ясаган ачыштан кинәт йөрәгә тартып куйды, ул табиб кына түгел, ә гашыйк ир заты иде. Рушаниянең язмышы азмы-күпме аның кулында, тик ничаклы гына тырышмасын, ул Алла түгел шул, ул да Алланың бер иярчен колы гына. Самат үзе ясаган ачыштан үзе дә авызын ачып калды. Бүтән карап утыра алмыйча, машинадан чыгып читкәрәк китеп басты, нигәдер аны да авыр кичерешләр бер почмакка китереп кысрыклагандай булды, авыр сулап куйды. Рушания белән танышканнан бирле ул аны үз туганы кебек күрә, җитмәсә, алар икесе генә белгән сер дә аларны якынайта, инде сүзсез аңлашырга өйрәнеп беттеләр. Ходайның кодрәте киң диләр, киндер шул, кешеләр белән ни теләсә шуны эшли. Ул кабат Ильяга борылып карады, кирәк идеме соң егеткә бу газаплар? Болай да эшләгән урыны газап диңгезе, нәр кеше гомере өчен көрәшә, күпме кешенең үзен генә түгел, гаиләләрен дә ятимлектән саклап кала. Шундый кешегә дә ник кирәк иде бу газап, беткәнмени сау-сәламәт хатын-кызлар? Ул бит аның киләчәген яхшы күзалдына китерә, Рушаниянe ни көткәнне белсә, бер ул гына белә. Белә торып шундый хатынга гашыйк булу, күрәләтә торып ярдәм итә алмау - эх, язмыш... Мәхәббәтне теләп тә, сорап та алып булмый, урамга чыгып кычкырып эзләсәң дә таба алмыйсың. Ә менә Монда? Әйе, Ходайның кодрәте киң, ни теләсә - шуны эшли, кирәк идеме соң бу яшь ир-егеткә мондый сынау, мондый газаплар?

Ә сентябрь айларында Илья Ильич Рушаниянe кабат клиникага чакыртып китерде. Рушания икенче катка бик әкрен генә күтәрелде, килгән саен бәлки бу соңгысыдыр, дип килде. Кирәкле кабинетның ишек алдында әзрәк тын алыйм, кеше күзенә күренгәнче, дип туктавы булды, ишек ачылып китте. Әйтерсең, Илья кәтеп торган, бик текәлеп Рушаниянең йөзенә карап торды, аннан акрын гына кулын сузып, аны култык астыннан эләктереп алды.

- Хәлләр начар, бүген монда каласың, Рушания ханым. Болай йөреп булмый, озакламый торып йөри дә ала алмассың,- дип, акрын гына кертеп йомшак креслога китереп утыртты, тагын текәлеп карап торды. - Хәлең ничек дип сорамыйм, болай да күрәп торам. Сиңа бер ун көнгә ятарга туры киләчәк, химиясез ич ярамый, монда ирегезнең ризалыгы да кирәк.Рушания сискәнеп китте.

- Юк, мин аның белүен теләмим.

- Кем дә булса, бер якын кешең кул куярга тиеш.

- Үзең куй, ничьюгы Самат куйсын, тик өйдә белмәсеннәр. Белсәләр, мин ятмыйм да, беткән бетсен тизрәк бу газаплар.

- Рушания, әле көрәшергә кирәк, булган мөмкинчелекләрнең барысын да кулланырга кирәк. Илья йомшак кына итеп аның кулыннан алды, күзләренә текәлеп карап торды.

- Көрәшик, бирешмә әле, мин һәрвакыт синең белән. Ишектә олы гына яшьтәге бер кеше күренде.

- Мөмкинме?

- Кер, әти, кер. Таныш бул, бу минем әти була, без коллегалар.

Ак чәчле, күпне күргән табиб ипләп кенә Рушания янына килеп утырды, ул да улы кебек текәлеп карап торды.

- Рәхсәт итсәгез, мин сезне үзем карар идем. Күлмәк изүегезне генә ычкындырыгыз. Карт табиб куллары белән муен тиреләрен баскалап карады, аннан улының кулындагы кәгазьләргә күз йөртте. - ничшиксез ашыгырга кирәк иде.

Акрын гына кабат янына килеп утырды. - Беләсезме, чибәр ханым, сезгә бик ашыгыч химия терапия алырга кирәк, ул сезнең хәлегезне күпкә җиңеләйтәчәк. Сез хәзер таралып барган урындыкны хәтерләтәсез, ә дәвалау курсы үткәч, сез җиңеләеп йөгереп йөрячәксез, ярты елмы, бер елмы - сез бу чирләрдән котылып торачаксыз. Газапламагыз үз-үзегезне.

- Рәхмәт, тик бу вакытны сузу гына, бүген үлдең ни дә, иртәгә ни.

- О-о, чибәрем, ялгышасыз, якты дөньяның һәр көне кадерле, карт булсам да, анда мин дә ашыкмыйм. Эшләнмәгән күпме эшләр, күпме өметләр яши әле, күңел бер дә картаймый. Менә, мәсәлән, минем әле иң зур теләгем - менә шушы улымны өйләндереп, оныклар күрү бәхетенә ирешү, ә сезнең балаларыгыз бармы?

- Бар, икәү, мин дә бик теләр идем дә, өлгермәм шул.

- Алай төшенкелеккә бирелергә ярамый, кешенең тормышы бер көндә дә әллә нигә әйләнергә мөмкин. Кызыгыз бармы?

- Бар.

- Ә сез беләсезме, кыз баланы матур кәләш киемендә күрү ниндибәхет икәнне? Сезнең балагыздан да матур кәләш юк кебек. Ә оныклар әби-бабай дип муеныңа сарылганны? Ә улың әнә-менә кәләш алып кайта дип көткәндә? Кеше һәр көнен өмет, көрәш белән яши. Тик сезнең хәлдә күп нәрсәләргә бик тыныч кararга кирәк, күп нәрсәләр сезнең кулда, чибәрем.

Рушания берни дә әйтмичә кайтып китте. Олы табибның үгете дә башыннан чыкмады. Чынлап та, бәлки язга кызы да кияүгә чыгып куяр, кем белә. Кем озатыр аны олы тормыш юлына? Аннан соңгы араларда онытып тора - Хәлимәнең балалары да аның ярдәменә мохтаҗ. Күпме эше, күпме үтисе вазыйфасы бар әле аның, ә ул гел Сашаны уйлап, башка берни турында да уйлый алмый. Көнчелек, рәнҗү аның акылын томалап алган, я Ходаем, ничек табарга моннан чыгу юлларын? Каян Хәлимәнең балаларына акча табарга да, ничек ун көнгә больницага кереп ятарга? Кинәт башына бер уй килде: тукта, аның туннары бар бит, шуларны сатып, балаларның укуына түләргә кирәк. Соңга калды микән, Лилия укуын ташлап чыкмагае. Тик кая барып, ничек итеп сатарга соң? Бәлки Анна ярдәм итәр. Әйе, ничшиксез, карт табиб хаклы, нәр көне санаулы, нәр көне кадерле. Рушания айнып киткәндәй булды, үз-үзен битәрләп тә куйды: булдыксыз мин, булдыксыз. Әллә ире артык кайгыртып шундый җебеккә әйләндергән, әллә үзе башта ук шундый булган, хәзер менә ансыз калгач, аннан башка берни белми, бер ни эшли алмый, үз-үзен җәлләп, елап утыра торган бер мескен бәндәгә әйләнде дә куйды. Юк, ул элек мондый түгел иде. Бала чагына кайтып, карт инәсе белән яшәгән чакларын исенә төшерде. Ул кичерә алмаган Фатыйма инәсе аны ташлап, кеше балаларын үстергән. Тик ул аны исенә төшкән саен читкә куды. Шулай да, берәттән торган ике өйне, ике гаиләне бер-берсеннән башка күзалдына да китерү мөмкин түгел иде. Фатыйма әнисе ике гаиләне бергә тартты. Ул ялгыз карт әнисе белән генә үсте, шулай да алар кешедән ким-хур яшәмәделәр, ләбаса. Чыгу юлын эзләргә кирәк. Иң башта Хәлимәнең балалары турында кайгыртырга кирәк, аннан чынлап та, кызы белән сөйләшеп кararга. Бәлки өйләнешеп тә куярлар. Бермәлгә Рушания кызының туен күз алдына китереп, хыялланып куйды, нинди яхшы булыр иде! Карт табиб хаклы, аның кызы бер генә, олы юлга ак теләкләр теләп кем озатыр? Янында әнисе булмаса, күңеле сыныК булыр. Шул актык көчне җыеп булса да, яшәргә кирәк, ярты елмы, бер елмы, әллә ниләр эшләп өлгерергә була бит әле. Рушания өйгә кайту белән кышкы киемнәр эленеп торган шкафны ачты, күпме кием иде монда.

Хәлимә исән булса, боларның барысын да аңа бирер иде, теләсәң - ки, теләсәң - ябынып ят, дияр иде. Мескенем, ниләр әйтеп көлдерер иде икән? Хәлимә исенә төшкәч, кабат нәрсәседер кителгәндәй, эче пошарга тотынды. Алар бары берничә генә көн таныш булдылар, ә менә хәзер әйтерсең гомерлек якын туганын югалтты. Ул исән калсамы, алар аерылгысыз, апалы-сеңелле кебек яшәрләр иде. Рушания гади, беркатлы, ябык Хәлимәне исенә төшергән саен, иң кадерле кешесен югалткандай кысылып куя, йөрәкне әрнетеп нәрсәдер тырнарга тотына. Ул исән булсамы, нәрсәдер әйтеп аны шаккатырыр, көлдерер, юатыр иде. Юк шул, Хәлимә дә юк, бер якын туганы да юк. Менә кайда икән ул ялгызлык. Гомер буена сокланып, Алла урынына күреп яшәгән Сашасы да юк. Үлеп китсә, соңгы юлга озатыр якын кешесе дә юк. Я Ходай, карап торуга нинди бай тормышта яши, ни теләсә, шунысы бар кебек, ә төптән уйлап карасаң, ул ялгыз икән бит. Рушания калтыранып үз-үзен кочаклады, әйтеп бетергесез авыр хисләр буды. Авыр уйлар аның хәлен авырайтып җибәрде, кайнар тир бәреп чыкты, авызы кибеп, куллары ук калтырый башлады. Ул калтыранган куллары белән уколын эзләп тапты да кендектән түбән кадап җибәрде. Әзрәк торгач, тыныч лануын сизеп, торып утырды. Илья хаклы, берни дә уйламаска, төшенкелеккә бирелмәскә, юксаң, берни дә эшләргә өлгермәячәк. Рушания торып кабат кышкы киемнәре янына килде, күз алдында эленеп торган, әле полиэтилен пакеттан да чыкмаган зәңгәр норка тунын кулына алды, аның әле этикеткасы да салдырылмаган. Аны Саша былтыр җәй алып кайтып кидергән иде, искитмәле матур, тик кияргә ничектер җай чыкмады. Аннан, ул карасын ныграк ошатты, карасы йөзенә ныграк килешә кебек тоелды. Ул аны соңгы тапкыр киеп кararга булды. Соңгы вакытта әллә нык ябыкканлыктан, ул иркен һәм буш иде. Рушания ипләп кенә тунны салып, кире урынына элде, бераз карап торды. «Ярый, нинди-дер Мариналарны сөендергәнче, ятимнәрнең тамагын туйдырсын».

Рушания бик уңайсызланып кына Аннаның ишеген какты, аның башында бер уй - ничек итеп аңлатырга соң болай итеп кием сатып йөрүен? Чигенергә урын юк иде, уку елы күптән башланды.

- Сезгә кем кирәк? - дигәнгә Рушания борылып карады.

- Анна, исәнмесез, мин сезгә йомыш белән килгән идем.

- Тукта-тукта, исемегезне оныттым, Илья Ильич белән килгән идегез.

- Әйе, рәхмәт тануыгызга.

- Керегез, кер. Ялгышмасам, Рая исемегез.

Рушания елмаеп башын гына селкеде.

- Анна, мин сезнең ярдәмгә мохтаҗ, минем хәлне сез яхшы аңлыйсыз. Тик моны минем гаиләм белми һәм белергә дә тиеш түгел. Рушания дулкынланудан кулларын кая куярга белмәде, бите тирләп чыкты.

- Рая, беренчедән, тыныч лан, монда сөйләшкән монда калачак. Чирен яшергән бик тиз үлгән ди, син миңа калса, бөтен нәрсәне яшереп калырга тырышасың. Бу мөмкин түгел, чир бит ул синең йөзеңә чыга. Әгәр дә белмәсеннәр дисең икән, куркудан тукта, үзеңне кулга ал, үзеңне көчле кеше итеп сана. Шул чакта гына бу кешенең тормышы түгәрәк, бер кайгы-хәсрәтсез яши икән, диярләр. Анна өстәл өстенә бер уч дарулар чыгарып салды. - Менә мине дә нәрсә тота, көн дә учлап ашыйм, кичкелеккә хәлсез булып егылам. Шулай да, иң беренче минем балаларым, шушы эшем бар, миңа нык булырга кирәк. Чөнки менә монда эшләгән кешеләрне дә туйдырырга, өйдәге балаларны да куркытмаска, киләчәккә ныклап аякка бастырып өлгерергә кирәк. Рая, безнең чир белән безнең хәлдә һәр туачак якты көн өчен көрәшергә кирәк, аңлыйсыңмы шуны? Без аналар, без түземле булырга тиеш. - Анна Рушания янына килеп утырды да, иңеннән кочаклап алды, аның олы яшел күзләрендә яшь ялтырады.

- Әйдә, тыныч ланыйк та, тәмләп чәй эчик, яшел чәй бик файдалы, какшаган нервларны тыныч ландыра.

Дәвамы бар.

ИХТИРАМГА ЛАЕК ШӘХЕСЛӘР

ҮЗ ҖИРЕН, ҮЗ ХАЛКЫН ЯРАТУЧЫ

Кеше башкарган эшләре белән матур. Кешеләргә эшләгән яхшылык, үзеңне аямыйча, башкаларның тормышын кайгыртып, аларга ярдәм итүләр онытылмый. Мосеевка авылында гомер итүче Шәүкәт Дәүләтшович Давыдов та шундый олы йөрәкле, киң күңелле, бар яктан да үрнәк, язмышын авыл белән бәйләгән, олы ихтирамга лаек кеше. Туган авылына тугры хезмәт иткән Шәүкәт Дәүләтшович Давыдов 2 январьда гомер бәйрәмен билгеләде. Бу көнне һәрвакыттагыча аның янында гаиләсе, туганнары, дуслары иделәр.

Шәүкәт Дәүләтшович гаиләдә икенче бала булып туа. Хатирә апа һәм Дәүләтша абый гади кешеләр буларак, колхозда хезмәт итәләр. Кече яшьтән үк дүрт балаларында да бер-береңә ярдәм итү, олыларны хөрмәт итү кебек сыйфатларны булдырырга, хезмәткә мәхәббәт тәрбияләргә тырышалар, һәркайсын эшкә өйрәтәләр.

Шуңа күрә дә юбиларыбыз да ата-анасына лаеклы булып үсә. Авылның сигез еллык мәктәбен тәмамлап, район үзәгендә машина йөртүче курсларында белем туплап, таныклык ала. Шуннан соң яшь егет армия сафларына хәрби бурычын үтәргә китә. Биредә дә ул сынатмый, үзен үрнәк яктан гына күрсәтә, йөкләнгән эшен җаваплылык белән башкара. Авылга хәрби хезмәтен үтәп кайткач, Шәүкәт Дәүләтшович хезмәт юлын "Кирова" исемендәге колхозда шофер буларак башлап җибәрә. Монда да ул үзен бик булдыклы, үтә дә җаваплы хезмәткәр итеп таныта. Сәләтле егетне Сызран шәһәренә эретеп- ябыштыручы һөнәрен үзләштерергә юнәлдерәләр. Әлеге һөнәрне уңышлы үзләштереп, юбилярыбыз гомере буе авылда эретеп - ябыштыручы булып хезмәт куя. Ә бит әлеге авыр эшне бары тик үз җирен, үз халкын ихластан яратучы кеше генә җиренә җиткереп башкара ала. Үз эшен яратканга, вакыт белән санашмыйча, бер эштән дә зарланмый, күп көч таләп итә торган эшләрне дә үз өстенә ала. Өйләргә җылылык тоташтыруда да аның өлеше байтак. Үз авылын өзелеп сөю, туган туфрагына тугры булу аңа һәрвакыт җиң сызганып эшләргә көч-дәрт бирә, ул-үз эшенең остасы

Шәүкәт Дәүләтшович уңган, тырыш, бик сабыр, күркәм холыклы, дус-туганнарына гына түгел, авыл халкына да битараф булмаган, чын күңелдән, һәрвакыт хәлдән килгәнчә ярдәм итәргә тырыша. Мосеевкалыларга тимердән матур бизәкле йорт капкалары, аркалар ясауны да булдыра. Нинди эшкә алынса да, ул күңелен биреп эшли. Аның кулыннан килмәген эше юктыр, мөгаен. Авыл җирлегендәге техник агрегатларны язгы эшләргә әзерләүдә дә ул зур тырышлык куя. Йомыш белән килгән кешене беркайчан да кире кайтармый. Аны авыл халкы "безнең Кулибиныбыз", - дип тә йөртәләр. Үз кулы, үз көче белән хуҗалыкта бик кирәкле булган мини-трактор мосеевкалыларны гына түгел, күрше авылларны да таң калдыра. Әлеге транспорт аңа хуҗалыктагы эшләрне алып барырга ярдәм итә.

Ә инде күптөрле Рәхмәт хатлары, Почет грамоталары карусыз хезмәтенең бәяләп бетергесез җимешедер.

Шәхси тормышы да башкаларга сокланырлык. Гомерлек юлдашы, пар канаты булган Венера Камиловна белән 36 ел бергә бәхетле гомер итеп, бүгенге бер-берсенә булган ихтирам, мәхәббәт хисен саклап, бер-берсен күз карашыннан аңлап яшиләр. Венера Камиловна абруйлы укытучы, гомерен балалар укытуга, тәрбияләүгә багышлады. Кызлары Гөлназ, Әлфия, Гөлфия әти-әниләре үрнәкләрендә тәрбияләнеп, югары белем алдылар. Хәзер инде үз гаиләләре белән яшиләр. Шәүкәт Дәүләтшович оныкларына да ягымлы бабакай була белә. Алар - аның өчен иң зур куаныч.

Юбилярыбыз үзе турында "Гади кеше мин, авыл баласы, тормышымны да хезмәт белән яшәүгә кордым, бәхетемне дә шушы хезмәтемдә, гаиләмдә, балаларымда күрәм, шул гына!", - дип әйтә.Үрнәк гаилә башлыгы, яраткан әти һәм бабакай авылда хөрмәт казанган кеше. Моннан да олы бәхет бармы?!

Венера ХӨСӘИНОВА.
Мосеевка авылы.

ТУГАН ҖИРЕНДӘ ТАПКАН БӘХЕТ

Авыл җирендә һәркемнең тормышы, гаиләсе уч төбендә кебек күренә. Кемнең ничек яшәгәне, кемнең кем икәнлеге монда берәүгә дә сер түгел. Һәр авылның – үз уңганнары, атаклы кешеләре, үрнәк гаиләләре бар. Сүзем Яңа Терешка авылында яшәүче Фәрдәнә Абдулхаковна Фәтхуллина хакында.

Фәрдәнә ханым 1962 елның 8 январенда гади колхозчылар гаиләсендә дөньяга аваз салган. Әтисе Абдулхак абый Үмәров 42 ел дәвамында колхозда тирмәнче булып хезмәт итә. Әнисе Адилә апа, пенсиягә чыккончы, терлекчелек тармагында фермада эшләде. Тырыш, 4 балалы гаиләдә үскән Фәрдәнә кечкенәдән үк әти-әнисенең кул аларына кереп, барлык эшкә дә өйрәнеп үсә. Авыл мәктәбендә 8 сыйныфны тәмамлаган яшь кыз, Мәләкәс авыл хуҗалыгы техникумына укырга керә. Уңышлы гына хисапчы белгечлеген үзләштереп, туган авылына кайта һәм хезмәт биографиясен "Рассвет" колхозында хисапчы буларак башлап җибәрә. 1989 елда Урта Терешка авылында эшләп килүче район азык-төлек комбинатында хисапчы буларак хезмәтен дәвам иттерә. Авылның уңган-булган егете Илдар Фәтхуллин белән матур гаилә корып җибәрәләр. Тыйнак, акыллы, сабыр холыклы Фәрдәнә Фәтхуллиннарның гаиләсенә килен булып төшә. Фәрдәнә беренче көннән үк каенанасы Сәббиха Мостафовна белән дә уртак тел табып, дус һәм тату яшиләр. Тормышларын ямьләндереп, бер-бер артлы мәхәббәт җимешләре – кызлары Розалия белән Илмира туа. Балаларына дөрес тәрбия биреп, олы тормыш юлына бастырдылар. Розалия – медицина колледжын тәмамлады, кызы Каринаны һәм улы Тимурны үстерә, гаиләсе белән Сызран шәһәрендә яши. Илмира әнисе кебек үк хисапчы белгечлеген үзләштерде, Сызран шәһәрендә яши һәм улы Денисны үстерә.

Бүгенге көндә Фәрдәнә ханым авыл кибетендә сатучы булып эшли. Кибеттә эшләп авыл кешеләренә тагын да якынайды ул. Эшен җиренә җиткереп башкара. Бөтен авылдашлары белән уртак тел таба белә, һәммәсен дә ачык йөз белән каршы ала. Тормыш иптәше Илдар белән дә бер-бересен аңлашып яшиләр. Йорт тутырып терлек, кош-корт асрыйлар. Аларның гаиләләрендә тынычлык хөкем сөрә, күз генә тимәсен! Бәйрәмнәрдә ике як туганнары һәм балалары, оныклары кунакка кайтып йөриләр. Аларны кунак итеп, мунчалар кертеп, күчтәнәчләр белән озатып калалар.

8 январь көнне Фәрдәнә Абдулхаковна 55 яшьлек юбилеен каршы ала. Истәлекле юбилеең уңаеннан сиңа иң матур теләкләребезне юллыйбыз. Ходай Тәгалә сиңа авырмый, кайгы-хәсрәт күрми, озын гомер бирсен, гаилә шатлыгы, балаларыңның, оныкларыңның, якыннарыңның игелеген күреп яшәргә насыйп итсен. Ныклы тазалык, озын гомер, ак бәхетләр белән мул тормышта яшәвеңне теләп калабыз!

Фәрдәнә ЗАБИРОВА,
Урта Терешка авыл поселениесе Башлыгы.

ЗУР ГАИЛӘБЕЗНЕҢ ЯКТЫ КОЯШЫ

Һәр ир кеше үз гомерендә йорт салырга, агач утыртырга, ул үстерергә хыяллана. Урта Терешка авылында яшәүче Камил Абдулхак улы Сәйфетдинов та шундый хыяллар белән яшәгән. Югары Терешка авылының чибәр кызы Мәрьямны яратып гаилә коргач, аларның беренче балалары булып кыз туган. Анысы мин булам инде. Гөлфия дип исем кушканнар. Тормыш дәвам иткән, әниебез икенчегә бала туарга киткәч, әтиебез: "Монысы "обязательно" малай була", - дип очынып йөргән. Тик тудыру бүлегенә хәл белергә баргач: "Сезнең кызыгыз туды," дигәннәр.

Чибәр, бөдрә чәчле, кара күзле кызчыкка, җисеменә исемен туры китереп, Гүзәл дип исем кушканнар. Әтиебез ике кызын да күкрәгенә кысып, сөеп үстерсә дә, күңеленең бер почмагында: "Бәлки, әле малай да булыр", - дип хыялын тибрәтеп йөрткән. Әниебез дә тормыш иптәшен шатландырырга теләп, өченчегә йөккә узган: "Әтиләре, бер дә пошынма, өченчесе точно малай була", дигән. Улларын көтеп түземсезлек белән көннәрне санаганнар. Менә көткән көн килеп тә җиткән. Тик Сәйфетдиновларның өченчегә дә кызлары дөньяга аваз салган.

"Малай булмады инде",- дип кулын селккән әти. Димәк, кызларны бар һөнәргә дә өйрәтеп үстерергә туры килә. Нәкъ шулай итә дә инде әтиебез. Мин дә, Гүзәл дә, Кадрия дә мәктәптә яхшы билгеләргә генә укып, йорттагы эшләрне дә, өйдәгеләрен дә җиренә җиткереп башкарып үстек. Өчебез дә югары белем алып, һөнәрләр дә үзләштердек. Кызлары үсә – үсә күрше малайларның азгынлыгын күреп: "Әле ярый минекеләр кызлар",- дип тә шатланган вакытлары күп булды әтиебезнең.

Әтиебез үзе дә безнең өчен үрнәк тә, таныч та була белде. Мәктәптә гел яхшы билгеләргә генә укыганга күрә, безгә дәресләр әзерләргә булышып, бар белгәнен аңлатып, өйрәтеп үстерергә тырышты ул. Китаплар укырга ярата. Бар нәрсә белән кызыксынучан, уңган куллы, акыллы кеше. Авылның үрнәк гаилә башлыгы дисәм дә, ялгыш булмас.

Тик менә армия сафларыннан кайтып, читкә китеп югары белем алырга гына мөмкинлеге булмаган аның. Тол әнисен дүрт бала белән ялгызын калдырып китә алмаган. Шуңа күрә "Рассвет" колхозында механизатор булып эшләгән. Аның сәләтлелеген күреп, звеневой, бригадир итеп тә билгеләгәннәр.

Күрше Югары Терешка авылына командировкага җибәргәч, анда яңа гына бухгалтер һөнәрен үзләштереп кайткан Мәрьям исемле кызны күреп яраткан. Алар бик матур гаилә корганнар. Урта Терешка авылының "Рассвет" колхозы ике белгечкә йорт җиткереп биргән. Шунда гөрләшеп, тату гына яшиләр Сәйфетдиновлар гаиләсе. Йорт тутырып мал -туар асрыйлар. Бакчада да бар нәрсәне үстерәләр. Безнең әти белән әни бер - бересен күз карашларыннан ук аңлыйлар. Барлык эшләрне дә бергә башкаралар.

